ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ОКТЯБРЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ОКТЯБРЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

20.12.2021 — 79

Югары Ослан муниципаль районы
Октябрьский авыл җирлегендә гражданнарның
үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлегенең Октябрьский поселогы Школьная урамындагы 10 нчы күпфатирлы торак йортта яшәүчеләрнең 2021 елның 04 декабрендәге 4 номерлы җыенында кабул ителгән карарларны гамәлгә ашыру максатларында, Октябрьский авыл җирлеге Башкарма комитеты карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә калдырам.

.

Октябрьский авыл җирлеге
башлыгы: Ш.Р. Азизов

Октябрьский авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2019 елның 20 декабрендәге
79 номерлы карарына
1нче кушымта

Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе

1. Әлеге тәртип Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчалары 2020 елның 1 гыйнварыннан 2020 елның 31 мартына кадәр Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлегендә гражданнар җыенында катнашуларына һәм тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләренә карамастан, 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан түләнә.

3. Түбәндәге категория гражданнар үзара салым акчаларын түләүдән азат ителә:

а) Бөек Ватан сугышы инвалидлары;

б) Бөек Ватан сугышында катнашучылар.

4. Аерым категория гражданнар өчен түләү күләме гражданнар җыены турында карарда билгеләнгән сумманың 50 процентын тәшкил итә:

а) 1нче төркем инвалидлар,

б) күп балалы гаиләләр,

в)  көндезге  уку йортлары студентлары,

г) Бөек Ватан сугышы ветераннары

д) балачактан инвалидлар

5. Бер тапкыр түләү турында хәбәр итү (хәбәрнамә) бланкы имза яки почта элемтәсе аша юллау юлы белән гражданнарга җиткерелә.

Хәбәрнамәдә (хәбәр итү) гражданнарга үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

6. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акча Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге Башкарма комитетының шәхси счетына керә

7. Гражданнар тарафыннан түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру хокукына ия булган оешмалар аша почта күчерүен (исәп-хисап оешмалары) тормышка ашыруга яки Татарстан Республикасы дәүләт һәм https://uslugi.tatarstan.ru/. муниципаль хезмәтләр порталы аша башкарыла.

8. Касса ордеры, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслаучы башка документлар түләү фактын раслый.

9. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Октябрьский авыл
җирлеге
Башкарма комитетының
2019 елның 20
декабрендәге 79
номерлы карарына
2нче кушымта

ХӘБӘРНАМӘ (ХӘБӘР) № _______________

Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында

Түләүченең Ф. И. О.
_________________________________________________________________________

Адресы: _________________________________________________________________

Сезгә _______________________________________нигезендә ____________________

вакытында кадәр ________________________чараларны тормышка ашыру өчен бер тапкыр _________________ сум түбәндәге реквизитлар

буенча_________________________________________ түләргә кирәк.

Алучының банк БИК _____________________________

Сч. № ______________________________

Алучының сч. № ___________________________________

ИНН ___________________________________

КПП ___________________________________

КБК ________________ ОКАТО_____________

Түләү билгеләү
_____________________________________________________________________

Җитәкче _________________ ______________________________

(имза) (имзаны роасшифровкалау)

М. у.

- - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү сызыгы - - - - - - - - - - - - - - -

Хәбәрнамә (Хәбәр) № _________________
________________________________________________________________________

(муниципаль берәмлек исеме)

бюджетына үзара салым буенча _________________ суммада бер тапкыр түләү турында

Түләүченең Ф.И.О. ___________________________________

Адресы: _________________________________________________________________

Алган «__» ________________ 20__ ел___________________

( түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Аермалы кәгазь тутырыла һәм түләүчегә хәбәр шәхсән тапшырылса _______________ авыл җирлеге Башкарма комитетында кала .*